| СОВЕТ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ** | с.Старое Дрожжаное | **КАРАР** |

2021 елның 27 мае № 9/7

Авыл хуҗалыгы җирләрен хосусыйлаштыру вакытына билгеләнгән, гражданнар милкенә җир кишәрлекләрен түләүсез тапшыруның уртача район нормасы турында

Крестьян (фермер) хуҗалыгы эшчәнлеген дәүләт яки муниципаль милектәге җирләрдән башкару өчен милеккә бирелә торган җир кишәрлекләренең иң чик минималь күләмен билгеләү максатларында, Татарстан Республикасы Җир кодексының 34 статьясындагы 1 пункты һәм Татарстан Республикасы Җир кодексының 40 статьясындагы 2 пункты нигезендә, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән төзелә торган яңа җир кишәрлегенең минималь күләме, авыл хуҗалыгы җирләрен Чүпрәле муниципаль районының авыл хуҗалыгы предприятияләре чикләрендә гражданнарның милкенә түләүсез тапшыру йомгаклары нигезендә, Россия Федерациясе Президентының “Гражданнар милкенә җир кишәрлекләрен түләүсез тапшыру нормасын билгеләү тәртибе турында” 1992 елның 2 мартындагы 213 номерлы Указы һәм РСФСР Дәүләт Комитетының җир реформасы һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына ярдәм итү буенча 1992 елның 10 гыйнварындагы 3-15/51 номерлы хаты, шулай ук Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Министрлыгының 2020 елның 30 июлендәге 1-31/9412 номерлы хаты нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Авыл хуҗалыгы җирләрен хосусыйлаштыру вакытына билгеләнгән гражданнар милкенә җир кишәрлекләрен түләүсез тапшыруның уртача район нормасын 4,85 га күләмендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы урынбасары А.Е. Ярухинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе: М.Р. Гафаров